**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 сентябрь 2024ел № 408

**Әтнә районы Башкарма комитетының «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 21.07.2021 ел, №206 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210 - ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 14.07.2022 ел, №312-ФЗ Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»гы 28.02.2022 елның 175 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 21.07.2021 ел, №206 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның преамбуласында "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән” сүзләре белән алыштырырга;

1.2. административ регламентның 2.8.2. пунктының 8 нче подпунктында “Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы” сүзләрен “дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 10.11.2020 № п/0412” сүзләренә алмаштырырга.;

1.3. административ регламентның 2.8.2. пунктының 12 нче подпунктында “бакчачылык” сүзен “гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып баруы” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов